# Тема: Хәзерге заман хикәя фигыльнең мәгънәләре



# Хикәя фигыль турында раслаулар

| Дәрес башына кадәр | № | Раслаулар | Дәрес аза-гында |
|---|---|---|---|
| | 1 | Хикәя фигыль  эш яки хәлнең сөйләм вакытында (хәзерге), сөйләм вакытына кадәр (үткән) һәм сөйләм вакытыннан соң (киләчәк заманда) үтәлүен  яки  үтәлмәвен белдерә. | |
| | 2 | Хикәя фигыльнең  3 заман формасы бар. | |
| | 3 | Хәзерге заман хикәя фигыль – эш яки хәлнең сөйләм вакытында үтәлүен яки үтәлмәвен белдерә торган фигыль. | |
| | 4 | Хәзерге заман хикәя фигыль 2 төрле ясала:<br>1) –а, -ә<br>2) –ый, -и кушымчалары ярдәмендә | |
| | 5 | Хәзерге заман хикәя фигыль төрле  юнәлешләрдә килә, барлыкта-юклыкта килә, зат-сан белән төрләнә. | |
| | 6 | Җөмләдә хәбәр булып килә. | |
| | 7 | Хәзерге заман хикәя фигыль 4 төрле мәгънәдә кулланыла:<br>- сөйләп торган вакытагы эш яки хәлне белдерә;<br>- һәрвакыт булып торган яки кабатланган эш-хәлләрне белдерә;<br>- үткәндә булган эш хәлләрне җанландыру өчен;<br>- киләчәктә һичшиксез үтәләчәк эш-хәлләрне белдерү өчен | |



# Хәзерге заман хикәя фигыль 4 төрле мәгънәдә кулланыла:

1. Хәзерге заман хикәя фигыль сөйләп торган вакыттагы эш яки хәлне белдерә:

- Нигә болай бик әкрен **кайтасыз**, Талип абзый?

Мидхәт аны куып җитеп, янәшә атлап китте.

- Ишетәсеңме, нинди шәп **уйный**.



2. Хәзерге заман хикәя фигыль **һәрвакыт булып торган яки кабатланган эш-хәлләрне** белдерә:

1) Яфраклар **коела**, яфраклар...
Нәкъ шулай ел саен бу нәрсә...
Күбәләк шикелле талпынып
**Очалар**, аз гына җил бәрсә...

2) Крестьян баласы, ир бала булса, җиде яшьтән атка, тырмага, сабанга **йөри башлый**. Сигездә-тугызда утауга, уракка **кушалар**.



3. Хәзерге заман хикәя фигыль үткәндә булган эш хәлләрне җанландыру өчен дә кулланыла.

М-н, 922 нче елның маенда Болгарга ерак Багдаттан илче **килә**. Болгар рәсми төстә ислам дине **кабул итә** һәм заманында иң зур, көчле дәүләтләрнең берсе белән дипломатик мөнәсәбәтен **урнаштыра**.



4. Хәзерге заман хикәя фигыль **киләчәктә һичшиксез үтәләчәк эш-хәлләрне** дә белдерә ала:

- Менә нәрсә, Лотфулла абзый. Иртәгә бередә савучылар, терлекчеләр белән җыелыш **үткәрәбез**.



# Хәзерге заман хикәя фигыль 4 төрле мәгънәдә кулланыла:

1. сөйләп торган вакытагы эш яки хәлне белдерү өчен;
2. һәрвакыт булып торган яки кабатланган эш-хәлләрне белдерү өчен;
3. үткәндә булган эш хәлләрне җанландыру өчен;
4. киләчәктә һичшиксез үтәләчәк эш-хәлләрне белдерү өчен.



Мисаллардан күренгәнчә, хәзерге заманның мәгънәсе сөйләмдә, җөмлә эчендә ачыклана.

# Дәреслек буенча эш.

67 нче бит. 126 нчы күнегү.

Бирем: Тексттан хәзерге заман хикәя фигыльләрнең мәгънәләрен табып аңлату.

Үрнәк: яза - хәзерге заман хикәя



фигыль, үткәндә булган эшне белдерә, III зат берлектә.

- **Йөзә** – хәзерге заман хикәя фигыль, һәрвакыт булып торган эшне белдерә, III зат берлектә.



- **Кар ашый** - хәзерге заман хикәя фигыль, һәрвакыт булып торган эшне белдерә, III зат берлектә.



- **Өйрәтәме** - хәзерге заман хикәя фигыль, үткәндә булган эшне белдерә, III зат берлектә.



- **Белмисең** - хәзерге заман хикәя фигыль, сөйләп торган вакыттагы хәлне белдерә, II зат берлектә.



- **Болай итәм** - хәзерге заман хикәя фигыль, киләчәктә һичшиксез үтәләчәк эшне белдерә, I зат берлектә.



- **Кертәм -** хәзерге заман хикәя фигыль, киләчәктә һичшиксез үтәләчәк эшне белдерә, I зат берлектә.



- **Барам** - хәзерге заман хикәя фигыль, киләчәктә һичшиксез үтәләчәк эшне белдерә, I зат берлектә.



- **Алып кайтам** - хәзерге заман хикәя фигыль, киләчәктә һичшиксез үтәләчәк эшне белдерә, I зат берлектә.



- **Утыртам** - хәзерге заман хикәя фигыль, киләчәктә һичшиксез үтәләчәк эшне белдерә, I зат берлектә.




# Каршы күрше белән эш.

1. Кәгазьләрдә 4 фигыль язабыз. Шуның 3 се – хәзерге заман хикәя фигыль булсын, 1 се – фигыльнең башка төркемчәсе булсын. Башка сүз төркеменннән булса да ярый.
2. Бу артык сүзнең астына сызабыз.
3. Партнерлар белән кәгазьләрне алмашабыз. Артык сүзнең астына сызабыз.



# Иңбаш күрше белән эш.

Артык сүз турында фикерләшү. 30 сек.



# Ял итеп алыйк







# Индивидуаль эш

Бирем: Хәзерге заманның киләчәк эш мәгънәсендә килүенә җөмләләр төзү.

№1

иртәгә, спортзал, түгәрәк

№2

иртәгә, Көзге бал, кызлар

№3

тиздән каникуллар

№4

кичкә, дәрес

№5

6 нчы дәрес, физ-ра дәресе, волейбол

№6

бүген, китапханә



# Тест. Хәзерге заман хикәя фигыльнең мәгънәләре.

1. Бу җөмләдә хәзерге заман хикәя фигыльнең кайсы мәгънәсе белдерелә:

**Бүгеннән без чын-чыннан үз эшебезгә тотынабыз.** (М.Ә.)

1) сөйләп торган вакыттагы эш яки хәлне белдерә;

2) һәрвакыт булып торган яки кабатланган эш-хәлләрне белдерә;

3) үткәндә булган эш хәлләрне җанландыруны белдерә;



4) киләчәктә һичшиксез үтәләчәк эш хәлләрне белдерә.

2. Бу җөмләдә хәзерге заман хикәя фигыльнең кайсы мәгънәсе белдерелә:

- **Нишләп йөрисең?**
- **Мин Ленаны эзлим, таба алмыйм.** (Ә.Б.)

1) сөйләп торган вакыттагы эш яки хәлне белдерә;
2) һәрвакыт булып торган яки кабатланган эш-хәлләрне белдерә;
3) үткәндә булган эш хәлләрне җанландыруны белдерә;
4) киләчәктә һичшиксез үтәләчәк эш-хәлләрне белдерә.



3. **Хатны укыгач, Гатаулла абзый юлга чыга** җөмләсендә хәзерге заман хикәя фигыльнең кайсы мәгънәсе белдерелә:

1) сөйләп торган вакыттагы эш яки хәлне белдерә;

2) һәрвакыт булып торган яки кабатланган эш-хәлләрне белдерә;

3) үткәндә булган эш хәлләрне җанландыруны белдерә;

4) киләчәктә һичшиксез үтәләчәк эш-хәлләрне белдерә.



4. Бу җөмләдә хәзерге заман хикәя фигыльнең кайсы мәгънәсе белдерелә:

**Шапырай карт җәйләрен ферма көтүен көтә, ә кышларын каравылда тора.** (М.Х.)

1) сөйләп торган вакыттагы эш яки хәлне белдерә;

2) һәрвакыт булып торган яки кабатланган эш-хәлләрне белдерә;

3) үткәндә булган эш хәлләрне җанландыруны белдерә;

4) киләчәктә һичшиксез үтәләчәк эш-хәлләрне белдерә.



# Җавапларны тикшерәбез.

1. 4
2. 1
3. 3
4. 2



# Хикәя фигыль турында раслаулар

| Дәрес башына кадәр | № | Раслаулар | Дәрес азагын-да |
|---|---|---|---|
| | 1 | Хикәя фигыль эш яки хәлнең сөйләм вакытында (хәзерге), сөйләм вакытына кадәр (үткән) һәм сөйләм вакытыннан соң (киләчәк заманда) үтәлүен яки үтәлмәвен белдерә. | |
| | 2 | Хикәя фигыльнең 3 заман формасы бар. | |
| | 3 | Хәзерге заман хикәя фигыль – эш яки хәлнең сөйләм вакытында үтәлүен яки үтәлмәвен белдерә торган фигыль. | |
| | 4 | Хәзерге заман хикәя фигыль 2 төрле ясала:<br>1) –а, -ә<br>2) –ый, -и кушымчалары ярдәмендә | |
| | 5 | Хәзерге заман хикәя фигыль төрле юнәлешләрдә килә, барлыкта-юклыкта килә, зат-сан белән төрләнә. | |
| | 6 | Җөмләдә хәбәр булып килә. | |
| | 7 | Хәзерге заман хикәя фигыль 4 төрле мәгънәдә кулланыла:<br>- сөйләп торган вакыттагы эш яки хәлне белдерә;<br>- һәрвакыт булып торган яки кабатланган эш-хәлләрне белдерә;<br>- үткәндә булган эш хәлләрне җанландыру өчен;<br>- киләчәктә һичшиксез үтәләчәк эш-хәлләрне белдерү өчен | |



1. “Дәрес башына кадәр” һәм “Дәрес азагында” дигән баганаларны чагыштырыгыз. Сезнең фикерләр үзгәрдеме? Ни өчен?

________________________________________

2. Кайсы раслаулар сезнең өчен иң мөһиме? Ни өчен?

________________________________________



# Йомгаклау өлеше.

- Бүген дәрестә нәрсә өйрәндек?
- Нинди темаларга сөйләштек?



# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

